| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КЕРЛИГАЧСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КИРЛЕГӘЧ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2019 елның 15 октябре №28

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Кирлегәч авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 17 ноябрендәге 39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Кирлегәч авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы яңа редакциядәге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 16_1 статьясына һәм нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Кирлегәч авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 5 бүлеге нигезендә Кирлегәч авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Кирлегәч авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 39 ноябрендәге 42 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Кирлегәч авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы яңа редакциядәге Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 бүлекнең 1 пунктындагы 5 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлек башкарма комитеты җитәкчесе һәм җирле үзидарәнең махсус вәкаләтле вазыйфаи заты яшәү урыны буенча яки тиешле җирлектә, торак пунктта теркәлгән затлар өчен түбәндәге нотариаль гамәлләр кылырга хокуклы:»;

4 бүлекнең 1 пунктындагы 5 пунктчасының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

4 кисәкнең 1 пунктындагы 5 пунктчасының 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) күчемсез милек белән идарә итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышаныч кәгазен раслау;»;

4 кисәкнең 1 пунктындагы 5 пунктчасының 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мирас милке исемлеген җитештерү юлы белән мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрү;»;

в) 4 бүлекнең 1 пунктындагы 5 пунктчасының икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе закон актлары белән җирлек башкарма комитеты җитәкчесе һәм җирле үзидарәнең махсус вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан башка нотариаль гамәлләр башкару хокукы бирелергә мөмкин.»;

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә яңа редакциядә үзгәрешләр кертү хакында» карарны теркәү урынында теркәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Кирлегәч авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы, Совет рәисе С.Р.Сәлахова